РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«2» март 2021ел г. Альметьевск № 282

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 20 маендагы 954 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, хокукый мониторинг тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 20 маендагы 954 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 июлендәге 993 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге 94 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада карар:

2 бүлектәге таблицадагы 2.6 юлындагы 2 графадагы 5) пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) торак бинада яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган белешмәләр (документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән очракта);»;

3 бүлекнең 3.4.1.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1.5. Торак бинада яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган белешмәләр (документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән очракта);»;

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт

Зак. № 305-2000

күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымтаның 1 пунктында дүртенче һәм егерме икенче абзацларны төшереп калдырырга.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов